**Класс:** 7
**Укытучы:** Гыйләҗева Эльвира Зөфәр кызы
**Программа:** БИНОМ

**Тема:** Компьютерның программ тәэминаты. Систем программ тәэминат һәм программалау системалары турында
**Максаты**: Укучыларны программ тәэминаты,программ тәэминат типлары,гамәли программ тәэминат составы белән таныштыру.

**Дәрес барашы:**

-**Хәерле көн, укучылар!** Без бүген "Компьютерның программ тәэминаты. Систем программ тәэминат һәм программалау системалары" турында сөйләшәбез. Заманча персональ компьютерларның мөмкинлекләре шуның кадәр зур ки, аны эштә, укуда, көнкүрештә кулланучылар саны торган саен арта гына бара. Заманча компьютерның иң мөһим үзлеге – аның кулланучыга карата "дустанә" булуы. Кешенең компьютер белән аралашуы гади, күрсәтмәле һәм аңлаешлыга әйләнде.Компьютер кулланучыга теге яки бу очракта нишләргә кирәген үзе әйтә, катлаулы хәлләрдән чыгу юлларын күрсәтә.Моны исә программ тәэминат башкара.

Әйдәгез,кеше һәм компьютер арасындагы охшашлыктан файдаланып фикер йөртик. Яңа туган бала берни дә белми һәм бернәрсә дә эшли алмый диярлек. Белем һәм күнекмәләргә ул үсү, белем алу процессында,информацияне үзенең хәтеренә туплап ия була. Заводта микросхемалар, үткәргечләр һ.б. дан җыелган компьютер яңа туган балага охшаган. Компьютер хәтеренә программ тәэминат йөкләү баланы укыту процессына охшаган дип әйтергә мөмкин. Программ тәэминат программистлар тарафыннан ясала.

***Слайд 2***

Компьютер озак вакытлы хәтер җайланмаларында саклана торган барлык программалар җыелмасы **программ тәэминаты** (**программное обеспечение**) тәшкил итә.

Компьютерның программ тәэминаты даими рәвештә тулыландырыла,камилләштерелә.Заманча ПКда урнаштырылган программаларның бәясе еш кына аның техник җайланмалары бәясеннән кыйммәтрәк була. Заманча программ тәэминат эшләү программистлардан югары квалификация таләп итә.

Компьютерның программ тәэминатында шундый өлеш бар, компьютерда аннан башка берни дә эшләп булмый. Ул **систем программ тәэминат** дип атала. Систем программ тәэминатының төп элементы булып операцион система (мәсәлән Windows,Linux)тора. Сатып алучы систем программ тәэминаты куелган компьютер сатып ала, аның компьютер эше өчен мөһимлеге хәтер яисә процессорныкыннан ким түгел. Систем программ тәэминатыннан тыш, компьютерның программ тәэминаты составына **гамәли программалар һәм программалау системалары** керә.

**Компьютерның программ тәэминаты**

- **систем программ тәэминат;**
- **гамәли программ тәэминаты;**
- **программалар системаларына бүленә.**

Систем программ тәэминаты һәм программалау системалары турында сүз соңрак булачак. Ә хәзер гамәли программ тәэминаты белән танышырбыз.

***Слайд 3***

Кулланучыга үзенең информацион мәсьәләләрен программаламыйча гына чишәргә мөмкинлек бирүче программалар гамәли программалар дип атала.




***Слайд 4***

Операцион система белән бер комплектта, гадәттә, **гомумкулланышлы гамәли программалар** җыелмасы да куела. Windowsта бу “Стандарт” программалар төркеме (гади текст һәм графика редакторлары, калькулятор һ.б.), электрон почта программалары һәм интернет-браузер. Гомумкулланышлы программалар исәбенә шулай ук офис, мультимедиа һәм күңел ачу программаларын да кертергә мөмкин. Linuxта андый программалар, вазифаларына карап, төркемнәргә бүленгән.

***Слайд 5***

**Офис программалары.** Кагыйдә буларак , кулланучы, компьютер алганда, аңа офис программалар пакетын куя. Андый программаларга:

- текст процессорлары - текст документлары белән эш өчен;
- практикада киң таралган таблицалы исәп-хисап башкару өчен кулланыла торган таблица процессорлары;
- презентация - халык алдында чыгыш ясауда кулланыла торган демонстрацион видеорәт төзү программалары;
- катлаулы булмаган мәгълүмат базасы белән идарә итү программалары керә.

**Мультимедиа программалары.** Бу - сурәт һәм тавыш белән эш өчен тәгъдим ителә торган гомумкулланыш программалары. Аларга рәсем ясарга, фотоларны эшкәртергә, фотомонтаж ясарга мөмкинлек бирүче график редакторлар керә. Тавыш һәм сурәтләрне уйнатырга мөмкинлек бирүче программалар экранга сурәт чыгарырга, музыкаль язма тыңларга,

видеофильм карарга мөмкинлек бирә. Кагыйдә буларак, компьютерда тавыш эшкәртү белән, махсус программ пакетлар файдаланып, белгечләр шөгыльләнә.

**Күңел ачу программалары.** Күп кенә кулланучылар компьютер белән аралашуны компьютер уеннарыннан башлый.

**Профессиональ программалар.** Бу – **махсус билгеләнешле гамәли программалар –**һөнәри эшчәнлек кораллары. Мәсәлән, бухгалтер программалары бухгалтерияләрдә хезмәт хакын һәм башка исәп-хисапларны автомат рәвештә башкару өчен кулланыла;автоматлаштырылган проектлау системалары конструкторлар тарафыннан төрле техник җайланмалар проектларын эшләгәндә файдаланыла; катлаулы математик мәсьәләләр чишәргә мөмкинлек бирүче программалардан галимнәр һәм инженерлар файдалана; эксперт системалары табибка авыруга диагноз куярга ярдәм итә һ.б.

**Белем бирү программалары.** Бу шулай ук махсус вазифалы программалар. Аларга электрон дәреслекләр, тренажёрлар керә. Еш кына укыту максатларында уен формасы кулланыла. Бу кече яшьтәге балалар өчен аеруча нәтиҗәле санала.

***Слайд 6***

Систем программ тәэминатка, операцион системадан башка, күп кенә хезмәт күрсәтү, сервис программаларын кертергә мөмкин. Мәсәлән, бу дискларга хезмәт күрсәтү программалары, дисктагы файлларны тыгызлау, компьютер вирусларына каршы көрәш һәм башка бик күп төрле программалар.

Компьютер вирусы дип компьютердагы мәгълүматка зарар китерергә сәләтле яисә аны сафтан чыгара торган зарарлы программ кодны атыйлар.Вирусларны төп таратучылар булып лицензиясез программ тәэминат, очраклы чыганаклардан алынган файллар, шулай ук глобаль Интернет челтәре тора. Компьютер вирусларына каршы антивирус программалар төзү белән белгечләр шөгыльләнә.

***Слайд 7***

Систем һәм гамали программ тәэминатыннан тыш программ тәэминатның тагын бер төре бар. Ул программалау сисматемалары дип атала.

**Программалау системасы** – программалау телләренең берсендә эшләү өчен билгеләнгән инструменталь чаралар комплексы.

Программалау системалары белән программистлар эшли. Алар компьютер программалары төзи. Программалау телләре бик күп төрле, мәсәлән, Паскаль, Бейсик, Си һ.б. Шушы телләрдә программист программалар яза, ә программалау системалары ярдәмендә аларны компьютерга кертә, көйли, сыный, башкара.


Укучылар без бүген программ тәэминаты ,аларның типларын белдек. Шулай ук гамәли программа, мультимедиа, күңел ачу, профессиональ, белем бирү, сервис программалары турында да сөйләштек.

**Шуның белән, укучылар, темабызның теория өлеше тәмам, киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз.**

**-Хәерле көн, укучылар!** Компьютерның программ тәэминаты. Систем программ тәэминат һәм программалау системалары турындагы теманың практик өлешенә күчәбез.

***Слайд 8***

1 нче бирем.




Дөрес җавапны тикшерегез

***Слайд 9***




***Слайд 10***




| Программ тәэминаты | Мәсәлән |
|---|---|
| Архиватор | |
| Текст редакторы | |
| Электрон таблица | |

***Слайд 11***




| Программ тәэминаты | Мәсәлән |
|---|---|
| Архиватор | WinRar |
| Текст редакторы | Блокнот |
| Электрон таблица | MS Excel |


***Слайд 12***




***Слайд 13***

**Җавап юк.**

***Слайд 14***




***Слайд 15***

**Дөрес җавап: каспер антивирусы .**

**Шуның белән,  укучылар, дәрес тәмам , киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз.**